| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>БОЛЬШЕТУРМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ТЕТЮШСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ТӘТЕШ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ТОРМЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

тел. (84373) 57-3-12, факс 57-3-12

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**19 .11. 2021** **№ 7**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Чулла торак пунктында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Олы Тормы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Чулла авылы, Иванов урамы, 10 нчы йорт адресы буенча 2021 елның 2 декабрендә 09 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Чулла торак пунктында 2022 елга гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге Чуллы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Чулла т. п. юлларны грейдлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Чулла т. п. территорияне җәй көне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);».

«КАРШЫ» «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/ , https://pravo.tatarstan.ru/-.

5. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә, Татарстан

Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) белән авыру очракларының барлыкка килүен һәм таралуын кисәтү өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларны (COVID-19) үтәүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Н.Г. Салихов**